# КАРАР

**“24” ноябрь    2019 ел                                                                   №7**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Сәрдәбаш  авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 24 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:
«Сез 2020 елда  яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы  Шушмабаш авыл җирлеге  Сәрдәбаш  авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган  кешегә, түләү күләме 200 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1 нче төркем инвалидлардан, 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:
- юл-урам челтәре нигезен вак таш-грунттан каплау Сәрдәбаш авылы, Җиңүнең 65 еллыгы урамы-103 м, Маршал Жуков урамы-30 м,  Тукай урамы-103м;
- Сәрдәбаш авылында  чүплекне  бетерү?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

« ӘЙЕ»                                        “КАРШЫ“

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 221 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 130 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 130 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Сәрдәбаш авылында халык  җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2020 елда  яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Шушмабаш  авыл җирлеге  Сәрдәбаш  авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган  кешегә, түләү күләме 200 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1 нче төркем инвалидларга,  70 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- юл-урам челтәре нигезен вак таш-грунттан каплау Сәрдәбаш авылы, Җиңүнең 65 еллыгы урамы-103 м, Маршал Жуков урамы-30 м,  Тукай урамы-103м;

- Сәрдәбаш авылында  чүплекне  бетерү?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

ӘЙЕ»  - 130 “КАРШЫ“-0

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Сәрдәбаш  авылы, Җиңүнең 65 еллыгы урамы, 28 йорт, Тукай  урамы, 1а йорты  адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Шушмабаш  авыл җирлеге  башлыгы В.В.Сәгыйтов